**Нәбиуллина Г.Ә, Галимова Г.Н.**

*Казан федераль университеты*

# ТӨРКИ ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ РУХИ КЫЙММӘТЛӘРНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*В статье рассматриваются вопросы вербазизации морально-этических ценностей в тюрских пословицах.*

*пословица, тюрский народ, морально-этические ценности, духовная культура.*

*In the article discusses the questions of verbalization moral and ethical values in Turkish Proverbs.*

*proverb, a Turkic people, ethical values, spiritual culture.*

Дөньяда телсез яки җырсыз-моңсыз халык булмаган кебек, мәкальсез халык та юктыр дип уйлыйм, һәрбер халык сүз арасында мәкальләр кыстырырга ярата, үз телен аның белән бизи, төзи. Һәркайда, һәр халыкта үз мәкальләренә хөрмәт бар, аларга ышану, таяну бар. Безнең халыкта да шундый ук хәл: татар сөйләшкәндә сүз арасында урынына карап, фикерне куәтләү өчен кыска гына һәм килешле генә итеп, хикмәтле бер мәкаль әйтеп куя.

Кардәш төрки халыкларның кайберләре аны борынгылар сүзе, кайберләре — аталар сүзе, картлар сүзе дип атыйлар, татарларда – мәкальләр, чувашларда *ваттисем калани* — картлардан калган сүз дип йөртәләр. Халык үзе дә *Картлар сүзен капчыкка, яшьләрнекен янчыкка,* — диләр. Болардан мәкальләрнең, тәҗрибә һәм хикмәт җимеше буларак, хәтердә җыелып сакланырга тиешле булган бер хәзинә итеп каралуы аңлашыла. Һәм халык аны шулай үзенең хәтер капчыгында гасырлар буе саклап килгән дә.

Телнең аталар сүзе фонды мәдәниятнең көзгесе кебек, теге яки бу халыкның гореф-гадәтләре, кешелек кыйммәтләре, дөньяны аңлау һәм менталитет үзенчәлекләре турында зур күләмле мәгълүмат туплый.Мәкальләр халкыбызның тарихын да, язмышын да, аның табигатькә, җәмгыятькә мөнәсәбәтләрен дә, рухи дөньясын да, ышануларын һәм дөньяга карашларын да, акылын-фигылен, характерын, милли зәвыгын, теләкләрен, әхлагын һәм башка сыйфатларын да чагылдыралар. Мәкаль-әйтемнәрнең яшь буынны, гомумән, халыкны, әхлакый тәрбияләүдә роле аеруча зур. Мәкальләр аша без

төрки халыкның рухи йөзе, психологиясе турында кызыл җеп булып сузылып барган шактый кызыклы һәм эзлекле фикерләр ясый алабыз.

Максатыбыз төрки халык мәкальләрендә рухи кыйммәтләрнең чагылышын тикшерү. Чыганак итеп Özkul Çobanoğlu “Türk dunyası ortek atasözlere sözlügü” (2004), Metin Yurtbaşı Sınıflandırılmış Türk Atasözleri (1994); Gulnara Işkildina (2001) Nekı Isenbet ‘Tatar halık mekallere (2010) җыентыклары алынды.

Нәтиҗәләр:

1) Ата сүзләрендә туган җир, туган туфрак, газиз ана төшенчәләре янәшә куела. Мәсәлән, *tatr. Her koşnın uz oyası; ttü. Her kuş kendi yuvasını beğenir; başk. Üz ilin altın bişik; uygr. Her kımge ö yurtı eziz; kazr. Her kuşa öz yubası, her kese öz vatanı.*

2) Кешенең җәмгыятьтә ирешкән уңышлары хезмәткә мөнәсәбәте белән билгеләнә. Тормышның нигезе хезмәт булуын аңлаган хәлдә, төрки халыклар хезмәт сөюче, тырыш, эшчән, һөнәрле халык буларак гәүдәләнә. Хезмәтнең бәхет, шатлык, хөрмәт чыганагы икәнлеге күрсәтелә. (*tatr. Hezmet iyese - hurmet iyese; ttü. Gençlikde çalışırsan, yaşlılıkta rahat edersin; uygr. Yaşligidin ışle, keriganda çişle).*

3) Төрки халык өчен гаилә, туганлык - төп яшәеш кыйммәтләре. Төп игътибар балаларны тәрбияләүгә юнәлтелә. Бала - төрки халык өчен нәселнең дәвамчысы, яшәүнең мәгънәсе. Мәкальләрдән күренгәнчә, баланың холык-фигыле балачактан ук салына; әти-әни нинди булса, бала да шундый булып үсә дигән тотрыклы фикер яшәп килә. (*tatr. Oyada ni kurseng, oçkanda şunı kürırsın, kazk. Kus oyada neni kürse, uşkanda sonı aladı; krgz. Uyadan emneni körsö, uçkanda oşuonı alat; özbk. Küş uyasıda korganini oçkanda kiladi; ttü. Küş yavrusu yuvasında gördügünü yapar).*

3) Төрки халыклар өчен нәсел-ыру, туганлык мөнәсәбәтләре бик әһәмиятле. Иң төп таләп – кан-туганлык мөнәсәбәтләрен саклау, бер-береңә ярдәм итү, олыларны хөрмәт итү, шулай ук дуслык, бердәмлек, туганлашу хуплана. Мәкальләр олыларга игътибарлы, хөрмәтле булырга чакыра. (*tatr.*

*Olılarnın süzen totmasan, olayganҫı igılık kürmessın; ttü. Ululları ululayan kut bulur sözlerını tutmayan ulur; ҫağt. Ulıgnı uluglasa, kut bolur; balk. Ulu sözü dınleyen yüce daa aşar; kırm. Kart ögütü tutmagan kartaygaşı olmaz; özbk. Adam kariyalarnin yaşini hurmatlasa bahtlı boladi.)*

4) Төрки халыкларда рәхим-шәфкать, изге күңелле булу, тыйнаклык, миһербанлык кебек сыйфатлар мактала. Кешенең табигатен, характерын үзгәртү мөмкин түгел дип аңлатыла. Төрки халыкларның күзаллавы буенча кеше я миһербанлы, я явыз булып туа һәм яшәү дәверендә ул үзгәрми. (*tatr. İzgilik it de dingezge taşla balık biler balık bılmezse halik biler; ttü. İyilik et suya at balık bilmezse halık bilir; ҫağt. Yahşilik it deryaga taşla balık bilir balık bilmese halık bilir; balk. İilik yap denıze at balık bılmezse halek bilir; kazr. Yahşılık ele at deryaya balık bilmese halık biler; kırm. Eyilik ap da derüaga bırak balık bilmese halık beler; nogy. Yahşılık et te suvga tasla balık biler balık bilmese halık biler; krçy. igilik tas bolmaz; kklp. Jaksılık jerde kalmas özbk. Yahşilik yerde kolmas).*

Көнчелек, хөсетлек, явызлык кебек сыйфатлар тискәре сыйфатлар буларак күрсәтелә. Сагыш, үпкәләү, үкенү кебек хис-тойгылар тискәре сыйфатлар буларак күрсәтелә. Күңел төшенкелеге бәхетсезлеккә китерергә мөмкин дип искәртелә.

5) Әхлакый-этик кыйммәтләрнең үзәгендә намус, оят төшенчәләре тора. Кеше үз-үзен тота белергә, хисләре, сөйләме, гамәлләре өчен җавап бирергә тиеш. Хәйләкәрлек икенче акыл буларак мактала. Кеше төрле тормыш ситуацияләрендә үз акылы белән идарә итә белергә тиеш дип аңлатыла: *tatr. Akıl yaşta tüğel başta; ttü. Akıl yaşta değil başta; ҫağt. Akıl başda imes yaşdadır; balk. Akıl yaşta dilder baştadır; başk. Akıl yeşte tüğıl başta;kazk. Akıl casta emes başta; kırm. Akıl caşta tuvul baştadır; nogy. Akıl yasta tuvul basta.*

Сөйләм әдәбенә аталар сүзендә зур урын бирелә: ягымлы булу, такт саклау, аз сүзле булу мактала. Әңгәмәдәшчең белән конфликтка керү, тупаслык, ялган сөйләү, үз фикереңне әйтә алмау, буш сүз сөйләү, гайбәт тарату, мактану инкарь ителә: *tatr. Yahşı süz can azıgı naҫar süz baş kazıgı; ttü. İyi söz can azıgı*

*kötü söz baş kazıgı; başk. Yahşı hüz yen azıgı yaman hüz baş kazıgı; nogy. Yaman söz baş kazıgı yahşı söz yan azıgı; kırm. Yahşı söz can azıgı yaman söz baş kazıgı; özbk. Yahşı söz jon ozıgı yomon söz boş kazıgı.*

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, әхлакый, рухи тәрбия чарасы буларак, мәкальләр җәмгыять тормышында элек-электән гаять зур роль уйнап килгәннәр. Бу вазифаларын алар бүген дә югалтмаган. Шул рәвешле, төрки халыкларның аталар сүзе фонды әхлакый-этик канун булып тора. Төрки халыкның этнография һәм материаль культурасы хакында гына түгел, рухи йөзе, психикасы турында да мөһим нәтиҗәләр ясый алабыз. Мәкальләрнең гореф-гадәт, көнкүреш кагыйдәчелеге урынын тотып килүе аның бер өлеше әхлакый норма буларак роль уйнап килүен дә күрсәтә.

Аталар сүзе әби-бабайларның тәҗрибәсен, үгет-нәсихәтен, тәрбия алымнарын, буыннан-буынга күчеп килгән рухи мирасын өйрәнүгә нәтиҗә бирә. Халкыбызда элек-электән туган җир, туган туфрак, газиз ана төшенчәләре янәшә куелган.

Ата сүзләрендә төрки халыкларның рухи мәдәнияте, менталитеты, тормыш-көнкүреше бөтен тирәнлеге белән чагыла.